# Татарстан Республикасы ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасында кече эшкуарлык субъектлары өчен салым салуның, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның гадиләштерелгән системасын куллану турында**

1 статья. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге Закон кече эшкуарлык субъектлары – юридик затлар (алга таба – оешмалар) һәм юридик зат барлыкка китермичә, Татарстан Республикасы территориясендә «Кече эшкуарлык субъектлары өчен салым салуның, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның гадиләштерелгән системасы турында» Федераль закон нигезендә эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыручы физик затлар (алга таба – индивидуаль эшкуарлар) өчен салым салуның, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның гадиләштерелгән системасын куллану шартларын билгели.

Кече эшкуарлык субъектлары – оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар өчен салым салуның, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның гадиләштерелгән системасы Россия Федерациясе законнарында каралган һәм элек кабул ителгән салым салу, исәпкә алу һәм хисаплылык системасы белән бергә кулланыла.

Салым салу, исәпкә алу һәм хисаплылык системасын сайлап алу хокукы, гадиләштерелгән системага күчүне яки элек кабул ителгән системага кабат кайтуны да кертеп, кече эшкуарлык субъектларына законнарда каралган тәртиптә ихтыярый нигездә бирелә.

Әлеге Законның гамәлдә булуы кагыла торган оешмалар тарафыннан салым салуның, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның гадиләштерелгән системасын куллану законнарда билгеләнгән җыелма салымнар һәм җыемнар түләүне оешмаларның хисап чорына хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча исәпләнә торган берләшкән салым түләүгә алмаштыруны күздә тота.

ксп .тел 64-
4/ Гадил

Салым салуның, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның гадиләштерелгән системасын кулланучы оешмалар өчен таможня түләүләрен, дәүләт пошлиналарын, автотранспорт чараларын сатып алу салымын, лицензия җыемнарын, дәүләт социаль бюджеттан тыш фондларына түләүләрнең гамәлдәге тәртибе саклана.

2 статья. Салым салуның, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның гадиләштерелгән системасы субъектлары

Салым салуның, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның гадиләштерелгән системасы гамәли көче индивидуаль эшкуарларга һәм, гамәлгә ашырылучы эшчәнлегенең төренә карамастан, эшләүчеләренең саны (подряд шартнамәләре һәм граждан-хокукый характердагы башка шартнамәләр нигезендә эшләүчеләрне дә кертеп) 15 кешегә кадәр булган оешмаларга кагыла.

Оешмалар өчен эшләүчеләренең иң чик санына аларның филиалларында һәм бүлекчәләрендә эшләүчеләрнең саны да кертелә.

Салым салуның, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның гадиләштерелгән системасының гамәли көче акциз салына торган продукция җитештерү белән шөгыльләнүче оешмаларга, гамәлдәге предприятиеләрнең ликвидацияләнгән структур бүлекчәләре базасында төзелгән оешмаларга, шулай ук кредит оешмаларына, иминләштерүчеләргә, инвестиция фондларына, кыйммәтле кәгазьләр базарының һөнәри катнашучыларына, отышлы уен һәм күңел ачу бизнесы предприятиеләренә һәм үзләре өчен Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы тарафыннан бухгалтерлык исәбен һәм хисаплылыкны алып баруның махсус тәртибе билгеләнгән башка категориядәге хуҗалык итүче субъектларга кагылмый.

Салым салуның, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның гадиләштерелгән системасы эшчәнлекнең аерым бер төрләре өчен берләшкән салым түли торган эшкуарлык эшчәнлеге төрләре белән шөгыльләнүче оешмаларга һәм индивидуаль эшкуарларга кагылмый.

Әгәр салым салуның, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның гадиләштерелгән системасын куллану хокукына гариза бирелгән кварталга кадәрге ел дәвамында әлеге салым түләүченең тулаем керемнең гомуми күләме гариза бирелгән кварталның беренче көненә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең йөз мең минималь күләменнән артып китмәсә, кече эшкуарлык субъектлары әлеге Закон нигезендә салым салуның, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның гадиләштерелгән системасына күчү хокукына ия.

Салым салуның, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның гадиләштерелгән системасын куллану хокукына гариза биргән яңа төзелгән оешма яки яңа теркәлгән индивидуаль эшкуар аларны рәсми теркәгән кварталдан салым

282

салуның, исәпкә алуның, хисаплылыкның гадиләштерелгән системасы субъектлары булып санала.

3 статья. Салым салуның, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның гадиләштерелгән системасында салым салу оешмалары объектлары

Салым салуның, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның гадиләштерелгән системасында оешмалар өчен берләшкән салым салу объекты итеп хисап чорында алынган тулаем керем билгеләнә. Тулаем керем товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) реализацияләүдән алынган, хисап чорында реализацияләнгән мөлкәтне сату бәясеннән һәм реализациядән тыш алынган керемнәрдән җыелган сумма буларак исәпләп чыгарыла.

4 статья. Оешмалар өчен берләшкән салым ставкалары, аны түләү тәртибе һәм вакыты

Оешмаларның – салым салуның, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның гадиләштерелгән системасын кулланучы кече эшкуарлык субъектларының берләшкән салым ставкасы тулаем керем суммасының 10 проценты күләмендә билгеләнә һәм түбәндәгечә бүленә:

федераль бюджетка – тулаем керем суммасының 3,33 проценты күләмендә;

Татарстан Республикасы бюджетына – Татарстан Республикасының чираттагы финанс елына бюджет системасы турында Татарстан Республикасы законында билгеләнгән табышка салымны бүлү нормативлары буенча, Татарстан Республикасының республика бюджеты белән Татарстан Республикасы районнары һәм шәһәрләре бюджетлары арасында берләшкән салым суммасын бүлеп, тулаем керем суммасының 6,67 проценты күләмендә.

Оешма хисап чорындагы (кварталдагы) хуҗалык эшчәнлеге йомгаклары буенча хисап чорыннан соң килүче айның 20 числосына кадәр салым органына түләнергә тиешле берләшкән салымның исәбен, шулай ук, хисап чорында алынган тулаем керем суммасын күрсәтеп, керемнәрне һәм чыгымнарны (хисап чорының соңгы эш көненә булган хәлендә) исәпкә алу кенәгәсеннән күчермә тапшыра.

Салым органына күрсәтелгән документларны тапшырган чакта, оешма тикшерү өчен патент, керем һәм чыгымнарны исәпкә алу кенәгәсен, касса кенәгәсен, шулай ук хисап чоры өчен берләшкән салымны түләү турында (түләнгәнен раслаучы банк тамгасы белән) түләү поручениеләрен күрсәтә.

<u>5 статья.</u> Патент хакы һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан аны түләү тәртибе

Индивидуаль эшкуарлар тарафыннан салым салуның, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның гадиләштерелгән системасын куллану физик затларның эшкуарлык эшчәнлегеннән алынган керемнәренә федераль законнарда билгеләнгән салым түләүне әлеге эшчәнлек төре белән шөгыльләнү өчен бирелгән патент хакын түләүгә алыштыруны күздә тота.

Бер үк вакытта эшкуарлык эшчәнлегенең әлеге Законда билгеләнгән берничә төре белән шөгыльләнгәндә, патент әлеге эшчәнлекнең һәр төре буенча һәр патентның хакы күләменә туры китереп аерым-аерым түләнергә тиеш.

Индивидуаль эшкуарлар өчен патентның түләнелә торган еллык хакы, хисап чорындагы керемгә бәйсез рәвештә, беркетеп билгеләнгән түләү булып тора.

Индивидуаль эшкуарлар өчен патентның еллык хакы, эшчәнлек төренә бәйле рәвештә, түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Патентта күрсәтелгән эшчәнлек төре | Патентның еллык хакы күләме (мең сумнарда) |
|---|---|
| Азык-төлек товарларын җитештерү | 5,6 |
| Халык куллануы товарларын җитештерү | 3,0 |
| Реклама эшчәнлеге | 3,0 |
| Туристлык (шул исәптән халыкара) эшчәнлеге | 8,0 |
| Җәнлек мехы, тунлык сарык тиресе һәм күн чималын әзерләү һәм реализацияләү | 3,6 |
| Риэлторлык эшчәнлеге | 16,0 |
| Эшчәнлекнең башка төрләре | 18,0 |

Патент хакы һәр квартал саен тигез өлешләрдә агымдагы кварталның икенче аеның беренче көненә кадәр районнар һәм шәһәрләр бюджетына кертелә.

Ел дәвамында индивидуаль эшкуарлар эшкуарлык эшен туктаткан очракта, аванс белән түләнгән патент хакы эшчәнлек туктатылган кварталдан соң килүче кварталдан кайтарып бирелергә тиеш.

<u>6 статья.</u> Кече эшкуарлык субъектларының салым салуның, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның гадиләштерелгән системасына күчү тәртибе

Кече эшкуарлык субъектлары тарафыннан салым салуның, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның гадиләштерелгән системасын куллану хокукын

284

таныклаучы рәсми документ - чираттагы квартал башланганчы бер айдан да соңга калмыйча бирелә торган гариза буенча оешмаларны һәм индивидуаль эшкуарларны салым исәбенә кую урынындагы салым органнары тарафыннан бер календарь елга түбәндәге шартларны үтәгән килеш бирелә торган патент ул:

оешмада эшләүче хезмәткәрләрнең гомуми саны әлеге Закон нигезендә билгеләнгән чикне артып китмәсә;

оешманың узган хисап чорында салымнар һәм башка төрле мәҗбүри түләүләр буенча түләү вакыты үткән бурычы булмаса;

узган хисап чорына салымнар буенча тиешле исәпләүләр һәм бухгалтерия хисаплылыгы оешма тарафыннан вакытында тапшырылса.

Оешмаларны яки индивидуаль эшкуарларны салым салуның, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның гадиләштерелгән системасына күчерү яки, сәбәбе күрсәтелеп, күчерүдән баш тарту турында карар салым органы тарафыннан кече эшкуарлык субъекты гариза биргәннән соң унбиш көн эчендә кабул ителергә тиеш.

Салым органында патент алганда оешма яисә индивидуаль эшкуар теркәү өчен керемнәрне һәм чыгымнарны исәпкә алуның билгеләнгән рәвештәге кенәгәсен күрсәтә, анда оешманың исеме (индивидуаль эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме), башкарыла торган эшчәнлекнең төре (индивидуаль эшкуарлар өчен генә), урнашкан җире һәм банк учреждениеләрендә ачылган исәп-хисап һәм башка счетлар номерлары күрсәтелә. Салым органы керемнәрне һәм чыгымнарны исәпкә ала торган кенәгәнең беренче битендә патентның теркәү номерын һәм аны бирү көнен күрсәтә. Патент биргән вакытта шулай ук аның дубликаты да тутырыла, ул салым органында саклана.

Салым салуның, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның гадиләштерелгән системасы яңа төзелгән оешмаларга яки аны куллану хокукына ия булу өчен гариза бирүче яңа теркәлгән индивидуаль эшкуарларга рәсми теркәлгән кварталдан башлап кулланыла.

Патентның гамәлдә булу вакыты узганнан соң, оешманың яки индивидуаль эшкуарның календарь ел бетәргә унбиш көннән дә соңга калмыйча бирелгән гаризасы буенча, керемнәрне һәм чыгымнарны исәпкә алуның яңа кенәгәсен теркәп, чираттагы (еллык) гамәлдә булу вакытына патент бирелә.

Патентка һәм керемнәрне, чыгымнарны исәпкә алу кенәгәсенә Россия Федерациясендә гамәлдәге норматив актларда билгеләнгән хисаплылык кагыйдәләре кагыла.

Керемнәрне һәм чыгымнарны исәпкә ала торган кенәгәнең рәвеше һәм анда салым салуның, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның гадиләштерелгән системасын кулланучы кече эшкуарлык субъектларының хуҗалык гамәлләре Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

календарь ел беткәнчегә кадәр унбиш көннән дә соңга калмыйча, кече эшкуарлык субъектлары тарафыннан салым органына тиешле гариза кертелгән очракта, киләчәк календарь ел башыннан гамәлгә ашырыла.

Эшләүчеләрнең тиешле саны артып киткән очракта, салым түләүчеләр хисап тапшырылырга тиешле кварталдан соң килгән кварталдан башлап салым салуның, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның элек кабул ителгән системасына күчәләр.

7 статья. Салым салуның, исәпкә алуның һәм хисаплылыкның гадиләштерелгән системасын кулланучы кече эшкуарлык субъектларының җаваплылыгы

Әлеге Законны бозган өчен җаваплылык законнар нигезендә билгеләнә.

Патентны югалткан очракта, салым органы аның яңасын бирсен өчен хезмәткә түләүнең ике минималь күләмендә законнар нигезендә билгеләнүче штраф түләнү шарт.

8 статья. Йомгаклау нигезләмәләре

Әлеге Закон 2002 елның 1 гыйнвареннан, ләкин рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк түгел, үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президентына үз норматив хокукый актларын бу Законга туры китерүне тәкъдим итәргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерүне йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 28 июне
№ 944